| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2023 Баулы шәһәре №117

Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 115 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы, Баулы шәһәр Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 115 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (2019 елның 12 декабрендәге 124 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 132 номерлы,

2021 елның 14 декбрендәге 45 номерлы, 2022 елның 26 маендагы 61 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

15 статьяның 3 пункты гамәлләрен 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатырга;

25 статьяның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, шәһәр Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә, бюджет чыгымнарының максатчан статьясы буенча, һәр программа буенча бюджет турында карар белән раслана.»;

бишенче абзацта «вакытында расланырга тиеш» сүзләрн «билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта расланырга тиеш» сүзләре белән алмаштырырга;

алтынчы абзацта «үз көченә кергән көннән алып ике ай» сүзләрен «агымдагы финанс елының 1 апреле.» сүзләре белән алмаштырырга.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында (http://bavly.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров